| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ГОРОДА БУИНСКА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БУА ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 28 » июнь 2016ел № 41

**«Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы электрон рәвештә дәүләт, муниципаль һәм социаль әһәмияткә ия хезмәтләр күрсәтүгә күчү планы турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 19 гыйнварындагы 21 номерлы карары, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Буа шәһәре Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1.Расларга:

1.1. Агачларны һәм куакларны кисү, кронировкалау яки утырту өчен рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты, (1 нче кушымта);

1.2. Торак бинаны үзгәртеп коруга һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты, (2 нче кушымта);

1.3. Белешмә (өземтә)бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты, ( 3 нче кушымта);

1.4. Торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган (торак) торакка күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәрнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (4 нче кушымта);

1.5. Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урыннары алмашу буенча документларны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (5 нче кушымта);

1.6. Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (6 нчы кушымта);

1.7. Социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль милектә булган торак урыны бирү буенча гражданга муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (7 нче кушымта);

1.8. Күпфатирлы торак йортның беренче катында урнашкан фатирда балкон (лоджия) төзүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (8 нче кушымта).

2. Буа шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 31 декабрендәге 84 номерлы, 2014 елның 3 мартындагы 17 номерлы карарлары үз көчләрен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Буа муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе А. А. Никифоров